**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№2707**
**27.05.2019**

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты тарафыннан комплекслы запрос ярдәмендә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәкләрдә күрсәтү гамәлгә ашырылмый торган муниципаль һәм дәүләт хезмәтләре исемлеген раслау турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ санлы Федераль законның 15.1 маддәсе 13 бүлегенең 2 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты тарафыннан комплекслы запрос ярдәмендә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәкләрдә күрсәтү гамәлгә ашырылмый торган муниципаль һәм дәүләт хезмәтләре исемлеген кушымтада каралганча расларга.
2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Аппараты Җитәкчесе Г.К. Әхмәтовага йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы И.С. Зуев

Башкарма комитетның
2019 елның 27 маендагы
2707 нче карарына
кушымта

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты тарафыннан комплекслы запрос ярдәмендә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәкләрдә күрсәтү гамәлгә ашырылмый торган муниципаль һәм дәүләт хезмәтләре
исемлеге

| | |
|---|---|
| 1. | «Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» ярдәмче программасы буенча исәпкә кую һәм торак сатып алуга (төзүгә) социаль түләү алу хокукы турында таныклык бирү. |
| 2. | Җир эшләрен башкаруга ордер бирү. |
| 3. | Яр Чаллы шәһәре өстендә авиация эшләре, парашюттан сикерү, һава судноларының демонстрацион очышлары, пилотсыз очу аппаратларының очышлары, бәйләп куела торган аэростатларны күтәрү, шулай ук алар хакында белешмәләр аэронавигация мәгълүматлары документларында күрсәтелмәгән Яр Чаллы шәһәре чикләрендә урнашкан мәйданчыкларга төшү (очып китү) өчен рөхсәт бирү. |
| 4. | Муниципаль милектәге җир участогын аукцион формасында үткәрелә торган сатуларда арендага бирү. |
| 5. | Җир участогын аукцион формасында үткәрелә торган сатуларда сату юлы белән муниципаль милектәге җир участогын милеккә бирү. |
| 6. | Муниципаль милектәге җир участогын бакчачылык алып бару өчен гражданнарга милеккә (арендага) бирү. |
| 7. | Муниципаль милектәге җир участогын индивидуаль торак төзелеше өчен гражданнарга милеккә (арендага) бирү. |
| 8. | Аерылышуны дәүләт теркәвенә алу. |
| 9. | Язылышуны дәүләт теркәвенә алу. |
| 10. | Гражданнар хәле актларын дәүләт теркәвенә алу турында кабат таныклыклар бирү. |

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе Г.К. Әхмәтова